**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2010 елның 24 декабрендәге ПУ-856 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 29 декабрендәге ПУ-892 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1210 номерлы һәм 2015 елның 9 октябрендәге ПУ-979 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ 2016 елның 1 июленнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 30 май
№ ПУ-487

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның « 30 » маендагы
ПУ- 487 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасы

**Министр**

Муниципаль районнарда, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге районнарында территориаль органнар

Министр ярдәмчесе

**Министрның беренче урынбасары**
- Хезмәт мөнәсәбәтләрен жайга салу бүлеге
- Координацияләү һәм контроль бүлеге
- Мәгълүмати технологияләр, автоматлаштырылган системаларга техник хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү, мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү бүлеге
- Җир, мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлеге
- Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе бүлеге

**Министр урынбасары**
- Контроль-ревизия эше бүлеге
- Планлаштыру, финанслау һәм хезмәт өчен түләү бүлеге
- Дәүләт сатып алулары бүлеге
- Тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге
- Халыкның социаль регистрын формалаштыру бүлеге
- Социаль ярдәм чаралары аудиты бүлеге
- Пенсиягә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә өстәмә түләү билгеләү һәм түләү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге
- Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү бүлеге
- Хезмәт базары һәм дәүләт хезмәтләре мониторингы бүлеге
- Һөнәри белем һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Чаралар үткәрүне оештыру бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлеге
- Хәйрия эшчәнлеге секторы
- Инвалидлар белән эшләү бүлеге

**Эшләр идарәчесе**
- Административ-хуҗалык бүлеге
- Эш башкару бүлеге
- Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге
- Халык белән эшләү секторы

Юридик бүлек
- Бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге
- Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге
- Мобилизация әзерлеге, граждан оборонасы секторы